ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2022 Әгерҗе шәһәре № 13

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
Уразай авылында Салагыш елгасы аша күперне реконструкцияләү»
объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча
иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 46 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы, «Гавами тыңлауларны, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Уразай авылында Салагыш елгасы аша күперне реконструкцияләү» объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү срогы - 2022 елның 10 февраленнән 2022 елның 11 мартына кадәр;

2.2. Объектны планлаштыру һәм ызанлау проектын бастырып чыгару урыны - «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайты - http://agryz.tatarstan.ru.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарны 2022 елның 8 февралендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштыруны, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

3.2. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының

рәсми сайтында җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәрне (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

3.3. Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Советының административ бинасында линия объектын планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча экспозиция ачарга, шулай ук килүчеләргә 2022 елның 10 февраленнән 2022 елның 11 мартына кадәрге чорда экспозиция белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә (8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр);

3.4. 2022 елның 10 февраленнән 2022 елның 11 мартына кадәрге чорда идентификация узган килүчеләрдән фикерләшә торган проект буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кабул итәргә:

- язмача рәвештә: 22214, Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Салагыш ав., Ленин ур., 70 б.;

- проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә язма кертү юлы белән түбәндәге адрес буенча: 22214, Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Салагыш ав., Ленин ур., 70 б (8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр).

3.5. Проектны тикшерү нәтиҗәләре буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен һәм иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.6. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне 2022 елның 14 мартында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштыруны, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштыруны, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасары И.И. Ямалиевка йөкләргә.

Общий отдел
Гомуми бүлек

**А.Р. ВӘЛИЕВ**